ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2022 Олы Кайбыч ав. № 432

Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Кайбыч муниципаль районы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләре- яшь белгечләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалата түләүләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә дәүләт ярдәме һәм белгечләрне беркетү максатларында, «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада каралган Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Кайбыч муниципаль районы физкультура спорт оешмалары хезмәткәре- яшь белгечләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалата түләүләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы яшь белгечләргә ай саен өстәмә түләү бирү тәртибен» раслау турында 2019 елның 21 мартындагы 133 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 30 сентябрендәге
432 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Кайбыч муниципаль районы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләре- яшь белгечләренә акчалата түләүләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче Кайбыч муниципаль районының физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне бирү тәртибен һәм шартларын билгели:

ай саен эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1111 сум күләмендә, әмма аена 1111 сумнан артык булмаган өстәмә түләү;

хуҗалыкны төзекләндерүгә бер тапкыр түләнә торган акчалата түләү 20 000 сум күләмендә.

2. Оешмаларның хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә ай саен бирелә торган өстәмә түләүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Кайбыч муниципаль районы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән башкарыла.

3. Оешманың хезмәткәре - яшь белгече дип 35 яшькә кадәрге (35 яшьне кертеп), көндезге формада һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү программалары буенча дәүләт аккредитациясе алган югары белем бирү мәгариф оешмасын югары белем бирү программалары буенча - бакалавриат, белгеч, магистратура программалары (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү оешмасы) беренче тапкыр тәмамлаган һәм һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә хезмәт килешүе буенча һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча түбәндәге вазифаларга эшкә алынган Россия Федерациясе гражданы танылa: физкультура буенча инструктор, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор, тренер, тренировка процессы администраторы.

4. Айлык стимуллаштыру өстәмә түләве хезмәткәр - яшь белгечләргә эшкә урнашу аеннан соң килүче айның 1 числосыннан башлап билгеләнә һәм, әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфада өзлексез эшләгәндә, билгеләнгән датадан башлап өч ел дәвамында түләнә.

Хезмәткәр - яшь белгечләргә айлык өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар оешма приказы белән раслана.

Хезмәткәр - яшь белгечләргә айлык өстәмә түләү түбәндәге чорга озынайтыла:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә яисә альтернатив граждан хезмәтендә чакырылыш буенча хезмәт итү;

йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч яшькә җиткәнче бала карау буенча ял;

көндезге бүлектә аспирантурада уку.

5. Яшь белгеч әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфага башка оешмага күчкәндә, эштә 30 көннән дә артык булмаган вакытка тәнәфес ясау рөхсәт ителә.

6. Хезмәткәр - яшь белгеч хезмәткәрләр саны яисә штат кыскаруга бәйле рәвештә эштән чыгарылганда, , алга таба әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфага башка оешмага эшкә урнашканда, 60 көннән дә соңга калмыйча тәнәфес ясау рөхсәт ителә.

7. Хезмәткәр - яшь белгечләргә айлык өстәмә түләү яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Хезмәткәр - яшь белгечләргә айлык өстәмә түләү төп вазыйфасы һәм вазыйфасы буенча, әлеге хезмәткәр - яшь белгеч берьюлы ике эштә, ләкин бер ставкадан артыграк түгел, эшләгәндә билгеләнә.

9. Хезмәткәр - яшь белгечләргә айлык өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times \frac{H_f}{H_n},$$

монда:

D - хезмәткәр - яшь белгечләргә айлык өстәмә түләү күләме, сум;

P - хезмәткәр - яшь белгечләргә 1111 сум күләмендә айлык өстәмә түләү, сум;

Hf - хезмәткәр - яшь белгеч эшләгән сәгатьләрнең фактик саны, сәгать;

Hn - спорт резервын әзерләүне оештыру хезмәткәрләренең хезмәт хакының база ставкасы өчен сәгать нормасы, сәгать.

10. Хуҗалык төзекләндерүгә акчалата түләү хезмәткәргә бер мәртәбә бирелә.

11. Хезмәткәр оешма җитәкчесе исеменә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча хуҗалыкны төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза белән һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң эшкә урнашкан оешмада ике ел дәвамында эшләү вакытында мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Эшкә алынганнан соң ике ел вакыт үткәнчегә кадәр хезмәт килешүе туктатылган очракта, әлеге срок тәмамланганчы фактта эшләнмәгән вакытка пропорциональ рәвештә билгеләнгән күләмдә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өлешен кире кайтарырга тиеш.

12. Хуҗалык төзекләндерүенә бер мәртәбә акчалата түләү алу шарты булып хезмәткәрнең һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы тәмамлаганнан соң эшкә урнашкан оешмада ике ел дәвамында төп эш урыны буенча эшләү тора.

Хезмәт килешүе туктатылган очракта, аны эшкә алган көннән алып ике ел вакыт узганчыга кадәр, ул бер тапкыр түләнә торган акчалата түләүнең бер өлешен, күрсәтелгән срок тәмамланганчы калган фактта эшләнмәгән вакытка пропорциональ рәвештә кире кайтарырга тиеш.

13. Оешмалар ай саен, агымдагы айның 3 енә кадәр, Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт секторына документлар тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акчалар бирү турында гарызнамә;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча оешманың хезмәткәрләреннән - яшь белгечләреннән торган реестрлар.

14. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт секторы әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны карый һәм ай саен, агымдагы айның 5 еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына бюджетара трансфертлар бирү реестрын һәм заявкасын тапшыра.

Әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакеты яисә югарыда аталган пункт таләпләренә туры килми торган документлар тапшырылган очракта, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт секторы гаризаны кире кайтара һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, оешмага биш көн эчендә хәбәр итә.

Гаризаны кире кайтару турында хәбәр алынган көннән алып оешма әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәгән очракта кабат тапшыра.

15. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкару өчен оешма чыгымнарын финанс белән тәэмин итү күрсәтелгән максатларга оешмага субсидияләр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Субсидия Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты белән оешма арасында төзелә торган килешү нигезендә, муниципаль бюджет яисә автоном учреждениегә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Кайбыч муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү турындагы килешүнең типлашкан формасы нигезендә бирелә.

16. Күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар кергән саен, «Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ хезмәткәрләр - яшь белгечләргә акча түләүгә оешмаларның казначылык органнарында ачылган шәхси счетларына субсидияләр күчерә.

17. Оешмалар Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт секторына хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акча түләүгә субсидияләр куллану турында хисап бирәләр. 1

8. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләре Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш..

19. Оешма тарафыннан субсидияләр бирү шартлары бозылганда Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте секторының, физкультура һәм спорт секторының язма таләбе нигезендә, субсидияләр тиешле таләп алынган көннән алып 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына алга таба кире кайтару өчен, билгеләнгән тәртиптә Кайбыч муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш.

20. Субсидияләр бирү шартларын, шулай ук төзелгән килешүләрне оештыруны тикшереп тору Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, физкультура һәм спорт секторы һәм «Кайбыч муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан гамәлгә ашырыла.

21. Оешмалар хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирүне оешмалар билгеләгән хезмәт хакын түләү срокларында тәэмин итәләр.